
# FAMOUS RESERACHER, WRITER AND TEACHER

**Hatip Jusupovich Minnegulov,**
Kazan Federal University,
18 Kremlyovskaya Str., Kazan, 420008, Russian Federation,
Khatip.Minnegulov@ksu.ru.



**USMANOV (GOSMANOV) KHATIP USMANOVICH** (May 21, 1908, Sulmash village of Osinsky district, Perm Gubernia – February 14, 1992, Kazan), literary critic, writer, and Doctor of Philology (1962), Professor (1964), Honored Researcher of TASSR (1968).

In 1927–1935 he worked as a teacher of primary school in the village Sulmash, as the chief librarian of Sverdlovsk Tatar pedagogical school library, an employee of editorial offices of newspapers in Moscow and Kazan. He graduated from Kazan Pedagogical Institute (1939). He took part in the Great Patriotic War (1945–1946). After returning from the front, he taught at Kazan Pedagogical Institute (1946–1951). In 1951–91 he worked in Kazan State University, as the head of the Tatar Language and Literature Department (1951–1960), and after its division from 1960 to 1975 –as the head of Tatar Literature Department, Professor of Tatar Literature Department of KSU (1975–1989). He was a member of the Union of Writers of the Republic of Tatarstan (since 1939).

He is an author of monographic works on history of Tatar literature of the Middle Ages and Tatar poetry

**ГОСМАНОВ ХАТИП ГОСМАН улы** (21.05.1908, Пермь губ. Усы өязе Сулмаш авылы. – 14.02.1992, Казан), әдәбият галиме, язучы, филология фәннәре докторы (1962), профессор (1964), ТАССРның атказанган фән эшлеклесе (1968).

1927–1935 елларда Сулмаш авылы башлангыч мәктәбендә укытучы, Свердловскидагы татар педучилищесында китапханә мөдире, Мәскәү, Казан шәһәрләрендә газета редакцияләрендә әдәби хезмәткәр булып эшли, Казан педагогия институтын тәмамлый (1939). Бөек Ватан сугышында катнаша (1941–1946). Фронттан кайткач, Казан педагогия институтында өлкән укытучы (1946–1951). Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты (1951–1960), ул икегә бүленгәч, 1960 елдан 1975 елга кадәр татар әдәбияты кафедрасы мөдире, КДУның татар әдәбияты кафедрасы профессоры (1975–1989) вазифаларын башкара. ТР Язучылар берлеге әгъзасы (1939 елдан).

Урта гасыр татар әдәбияты тарихы, 1910–1920 еллар татар поэзиясе, әдәбият теориясе,

**УСМАНОВ (ГОСМАНОВ) ХАТИП УСМАНОВИЧ** (21.05.1908, д. Сульмаш Осинского у. Пермской губ. – 14.02.1992, Казань), литературовед, писатель, докт. филол. наук (1962), проф. (1964), засл. деятель науки ТАССР (1968).

В 1927–1935 гг. работал учителем начальной школы в дер. Сульмаш, завбиблиотекой Свердловского татарского педучилища, в редакциях газет в Москве и Казани. Окончил Казанский педагогический институт (1939). Участник Великой Отечественной войны (1945–1946). После возвращения с фронта преподавал в Казанском педагогическом институте (1946–1951). В 1951–1991 гг. зав. кафедрой татарского языка и литературы в Казанском государственном университете (1951–1960), а после ее разделения с 1960 по 1975 год – татарской литературы, профессор кафедры татарской литературы КГУ (1975–1989). Член Союза писателей РТ (с 1939 года)

Автор монографических трудов по истории татарской литературы средних веков и татарской поэзии 1910–1920-х годов, теории литературы и тюрко-татарскому стихосложению, учебников по татарской литературе для средних

of the 1910–1920s, theory of literature and Turkic-Tatar versification; textbooks on Tatar literature for secondary schools. He became famous as the author of collections of poems, stories, and essays. He was awarded the orders of the Red Star, “Honor Badge”, and medals.

төрки-татар шигыре төзелеше буенча монографик хезмәтләр, урта гомуми белем бирү мәктәпләре өчен татар әдәбиятыннан дәреслекләр авторы. Шигырьләр, хикәяләр, очерклар җыентыклары белән танылган язучы.

«Кызыл Йолдыз», «Почет Билгесе» орденнары һәм медальләр белән бүләкләнгән.

школ. Получил известность как автор сборников стихов, рассказов, очерков. Награжден орденами Красной Звезды, «Знак Почета», медалями.

Khatip Usmanovich was born in a family of a spiritual minister in Tatar region at Kazan-Sverdlovsk railway – Sulmash village of Osinsky district, Ryabki volost of Perm Gubernia (nowadays it is Chernushka district of Perm region) in May 21, 1908. His father had many children, was the head of a family of ten people, in addition to his basic duties, he grinded grain, bred cattle. He was heavily-built, surprisingly industrious, and took prizes in Sabantuys (ethnic festivals) of his district. Khatip Gosman also was a single-minded, and talented person. Apparently, he took after his father.

First Kh. Gosman studied in his village medrese, then – at a seven-year Russian school. In 1926, the future professor arrived in Kazan which was a center for Tatars and was enrolled at a preparatory couse, Tatar Rabfak. In 1920–1940, because of a great attention paid to people’s origin, his roots coming from a spiritual family were found out and in 1927 he was expelled from Rabfak. Kh.Gosman was subsequently subjected to various persecutions because of his social origin and expelled from the Komsomol party several times, but in spite of it, he never gave up: he was determined to struggle and carried on proving his rightness. In 1927–1929 he was known to work as a teacher of primary school in the village of Sulmash, then he worked at Kazan labor exchange as a teacher of illiterate people, ‘liquidator’ of illiteracy. In 1929–1930 and in 1933 he was the chief of Sverdlovsk Tatar pedagogical school library and translated for the newapaper “Sotsializm yuly”, in 1934–1935 he worked as an executive secretary of the newspaper “Stalinchy” which was published in Astrakhan (he got this job with the help of Musa Jalil). During these four or five years Kh.Gosman worked in the editorial offices of such newspapers as the “Eshche”, the “Communist” (it was a continuation of the “Eshche”) in Moscow and the “Yash stalinchy” in Kazan.

Being very good at literature from his young age, Khatip Gosman made several attempts to enter Kazan Pedagogical Institute to get a higher philological education. In spite of the fact that he passed exams sucsessfully, he managed to fulfill his dream only in 1935. He worked really hard, studying at Language and Literature Department of the Institute, he was actively engaged in literary creative work and published collections of poems. After the graduation from the Institute, in 1939–1940, the qualified specialist and the owner of a Diploma with Honour taught in a newly opened two-year Yelabuga Teacher Trainung Institute, then he worked at the Department of Western Literature of the Kazan Pedagogical Institute as an assistant. The pedagogical experience gained there helped him to study European literature, aesthetics and philosophy more deeply and to consider Tatar literature in the context of world literature in his further research. In 1941, Kh. Gosman was also known to work as a literary worker at M. Gorky museum.

When the Great Patriotic War broke out, many Russian literary scholars, representatives of art were sent to the rear area– most of them lived in Chistopol and Kazan. But Kh. Gosman was among those Tatar scholars who went to the front. He went to the war on 13 July 1941, he returned back on 6 May 1946. During five years Kh.Gosman took part in different actions including hard battles on the territory of Germany as an officer, worked at editorial offices of different front newspapers (“Vatan Ochen”, etc.) and was a political comissar. He returned from the war as a captain awarded with the orders of the Red Star, “For the Victory over Germany”, “For the Capture of Kennigsberg” and other medals.

In 1946–1951 Kh. Gosman worked as a senior teacher at the Department of Western Literature of Kazan Pedagogical Institute. After successful defence of his thesis “Development of Hadi Taktash's aesthetic ideas” in 1951 he received a degree of a Candidate of Philology. In the same year the period of his activity connected with Kazan State University began – he was invited to the university to take the post of the Head of Tatar Language and Literature Department. When in 1960 this department was divided into two parts — the Department of the Tatar Language and Tatar Literature Department, he became Head of Tatar Literature Department and held the position till August 1975. In 1962 he defended his thesis “Social revolution and Tatar poetry” and in 1964 received full professorship. In 1975–1989 the scholar worked as a professor-consultant of Tatar Literature Department.

Kh. Gosman entered Tatar literary and cultural life in the 1930s as a poet. “Kh.Gosman’s love for the artistic word was brought up from his childhood. In their family their reigned books and literature. His elder brother Tagir Gosman-Sulmash (1900–1983) was a famous writer. His novels used to arouse keen interest among readers of the 1920–1930s. Besides, Kh. Gosman was very emotional and had a poetic nature. In

1931, his first collection of poems ("Kyrlar lirikasy") was published in Kazan [Gosman, 1931]" (author's tranlation. – *Kh. M.*) [Minnegulov, p. 5]. In the late 1960s Khatip Gosman mentioned that he started to write a novel about a scholar's life. His active literary work in 1930-1940s became a good school for him: it helped Kh.Gosman in his studies to understand and explain the art of speech better, to uncover the mystery of poetry and its power of impact.

In the cultural society Kh. Gosman was foremost known as a great literature scholar and mentor. The main object of his research was Tatar poetry of the 1910-1920s of the 20th century and its main representatives G. Tukay, M. Gafuri, S. Babich, Kh. Taktash, Kh.Tufan. On the basis of his dissertation research such monographs as "Tatar Poetry of the Great October Revolution and the Civil War Periods" (Gosman, 1960), "Tatar Poetry of the 1920s" (Gosman, 1964) were published. These works, after editing were reprinted as "The Life of Poetry" (Gosman, 1978) and "Stepping Out onto the Big Road" (Gosman, 1982).

Kh. Gosman conducted the study of the structure of Tatar-Turkic poetry, which required the depth of thought and great vigor, and worked particularly efficiently in this direction by publishing voluminous works: "Tatar Poetry: Historical Review" (Gosman, 1964), "The Structure of Poetry" (Gosman, 1973), "Ancient Sources of Turkic Poetry" (Gosman, 1984), "Turkic Poetry in the Middle Ages" (Gosman, 1987), etc. His research is characterized by a strong connection with literary and historical processes, theoretical depth and polemics of the spirit. The author shows the importance of mutual influence and interaction of literature of Tatar and other cultures while noticing ones influence on the historical development of another. However, according to the research, Tatar-Turkic poetry was formed, grew and gave rise to the great poet of Tukay primarily due to its own achievements, the rhythm of speech, proverbs, and sayings. Kh. Gosman's theoretical views on Tatar-Turkic poetry were not only recognized beyond the Tatar world but also in the entire Turkic-speaking world.

After defending his doctoral thesis, Khatib Gosman got interested in the legacy of ancient and medieval literature. "In 1969, with his direct involvement the poem "Khosrov and Shirin" of the medieval poet Kutb was published in two volumes written in Arabic script. In 1970, the epic "Sultan Jenjemya" of the poet of the $14^{th}$ century Khisam Kutib was published with commentaries, in 1980 together with Zainap Maksudova they published the manuscript of "Gulstan bit-turki" by Saif Sarai written in Arabic script" [Dautov, Rakhmani 2009: 407]. In 1966, 1967 he published two manuals for the works of 14th and 18th centuries. There was also a textbook on "Theory of Literature" for higher educational institutions, (Gosman, Mazhitov, 1980], and the textbook "Literature" addressed to the 10th grade students of secondary comprehensive schools, written with the participation of Kh. Gosman.

In addition to research and pedagogical activity Gosman was a well-known public figure of his time. He regularly presented on national culture, education and national matters at conferences and congresses. He showed the high status of the Tatar people and the level of development of its research at international forum-congresses. In 1997, in Alma-Ata, where I took part in the celebrations of the 100th anniversary of Mokhtar Auezov, I learned that in 1957, during the celebration of the 60th anniversary of the poet, Gosman participated as a representative from Tatarstan. Despite the past 40 years, the older generation of literary scholars in Kazakhstan remembered his fiery, meaningful speech. His many-sided knowledge, subtle perception of the poetic word allowed him to communicate and cooperate with prominent scientists, especially in the Turkic world.

Doctor of Philology, Professor, Honored Researcher of the Tatar Soviet Socialist Republic, Chevalier of the Order of the Red Star and Badge of Honor, writer, teacher, journalist and public figure Khatip Gosman is an excellent example of heroic service to the people and the nation.

**References**

Gosman, Kh. (1931). *Kyrlar lirikasy: shigyr'läp* [Lyrical Poetry of Fields: Poems]. 36 p. Kazan, Kazan un-ty näshr. (In Tatar)

Gosman, Kh. (1960). *Böyek Oktyabr' revolutsiyase häm Grazhdannar sugyshy chorynda tatar poeziyase.* [Tatar Poetry of the Great October Revolution and the Civil War Periods]. 182 p. Kazan, Kazan un-ty näshr. (In Tatar)

Gosman, Kh. (1964). *Yegermenche ellarda Tatar poeziyase* [Tatar Poetry of the 1920s]. 397 p. Kazan, Kazan un-ty näshr. (In Tatar)

Gosman, Kh. (1964). *Tatar shigyre: tarikhi küzätü* [Tatar Poetry: Historical Review]. 156 p. Tatar. kit. näshr. (In Tatar)

Gosman, Kh. (1975). *Shigyr'tözeleshe* [The Structure of Poetry]. 132 p. Kazan, Tatar. kit. näshr. (In Tatar)

Gosman, Kh. (1978). *Shigriyat gomere* [The Life of Poetry]. 208 p. Kazan, Tatar. kit. näshr. (In Tatar)

Gosman, Kh., Mäžitov, Z. (1980). *Ädäbiyat teoriyace. Әдәби äcäp: Urta mäktäplärneŋ tel-ädäbiyat ukytuchylary, studentlar häm yugary klass ukuchylary öchen kullanma* [Theory of Literature. Literary Work: A Manual for Secondary School Teachers, Students and Senoir Pupils]. Prof. I.Nurullin red. 143 p. Kazan, Tatar. kit. näshr. (In Tatar)

Gosman, Kh. (1982). *Oly yulga chykkanda* [Stepping Out onto the Big Road]. 256 p. Kazan, Tatar. kit. näshr. (In Tatar)

Minnegulov, Kh. Yu. (2002). *Khatip Usmanovich Usmanov*. 20 p. Vydaiushchiesia uchenye Kazanskogo unversiteta. Izd-vo Kazan.univ-ta (In Russian)

Usmanov, Kh. Yu. (1984). *Drevniye istoki tiurkskogo stikha: uchebnoe posobie* [Ancient Sources

of Turkic Poetry]. 152 p. Kazan’, izd-vo Kazan.univ-ta. (In Russian)

Usmanov, Kh. Yu. (1987). *Tyurkskii stikh v srednie veka* [Turkic Poetry in the Middle Ages].147 p. Kazan’, izd-vo Kazan.univ-ta. (In Russian)

Gosman, Kh. (2009). *Ädiplärebez: bibliographik beleshmälek: 2 tomda: 1 t.* [Our Men of the Pen: A Bibliographic Guide: In Two Volumes: Volume One]. Töz. R. N. Dautov, R. F. Rakhmani. 404–408 p. Kazan, Tatar. kit. näshr. (In Tatar)

# КҮРЕНЕКЛЕ ГАЛИМ, ӘДИП ҺӘМ ОСТАЗ

**Хатыйп Йосыф улы Миңнегулов,**
Казан федераль университеты,
Россия, 420008, Казан ш., Кремль ур., 18 нче йорт,
Khatip.Minnegulov@ksu.ru.

Хатип Госман улы 1908 елның 21 маенда Пермь, Казан–Свердловск тимер юлы буендагы татар төбәге – элеккеге Усы (Оса) өязе Рипкәү (Рябки) волосте (хәзерге Пермь өлкәсе Чернушка районы) Сулмаш авылында рухани гаиләсендә туган. Аның әтисе – күп балалы, ун кешелек гаилә башлыгы – төп хезмәт вазифаларыннан тыш иген иккән, мал асраган, таза гәүдәле, гаҗәеп тырыш кеше булган, үз төбәкләрендәге Сабантуйларында мәйдан тоткан. Хатип Госман да эре гәүдәле, максатчан, төрле һөнәрләргә һәвәс зат иде. Күрәсең, бу төр сыйфатлар аңа әтисеннән дә күчкән.

Х. Госман әүвәл үз авылындагы мәдрәсәдә, аннан Рипкәүдәге җидееллык рус мәктәбендә укый. Булачак профессор 1926 елда татар мәркәзе Казанга килә һәм Татар рабфагына укырга керә. 1920–1940 елларда кешенең нәсел-нәсәбенә гаять нык игътибар ителү сәбәпле, аның рухани гаиләсеннән икәнлеге беленеп, 1927 елда Х. Госман рабфактан чыгарыла. Социаль чыгышы аркасында ул, алга таба да төрле куылуларга, эзәрлекләүләргә дучар булып, берничә мәртәбә комсомолдан чыгарылса да аптырап калмый: көрәшә, үзенең хаклылыгын үҗәтләнеп акларга омтыла, алга бара. 1927–1929 елларда аның Сулмаш башлангыч мәктәбендә укытучы, Казан хезмәт биржасында грамотасызлыкны бетерүче булып эшләве мәгълүм. 1929–1930, 1933 елларда ул – Свердловскидагы татар педагогия училищесында китапханә мөдире һәм «Социализм юлы» газетасында тәрҗемәче; 1934–1935 елларда Әстерхан өлкәсендә чыга торган «Сталинчы»да җаваплы секретарь (Бирегә ул М. Җәлил ярдәме белән урнаша). Шушы дүрт-биш ел эчендә Х. Госман Мәскәүдәге «Эшче», «Коммунист» («Эшче»нең дәвамы), Казандагы «Яшь сталинчы» кебек газеталарда әдәби хезмәткәр вазифаларын башкара.

Кечкенәдән үк шигъри сүзгә мәхәббәте көчле булган Хатип Госман, югары филологик белем алу өчен, берничә мәртәбә Казан педагогия институтына керергә омтылып карый. Имтиханнарын уңышлы тапшырса да, бу теләгенә ул бары тик 1935 елда гына ирешә. Институтның тел-әдәбият бүлегендә ул, чын күңелдән бирелеп, гаять тырышып укый, әдәби иҗат белән актив шөгыльләнә һәм шигырь җыентыкларын чыгара. Югары мәктәпне тәмамлагач, белемле, кызыл дипломлы белгеч 1939–1940 елларда яңа ачылган икееллык Алабуга укытучылар институтында укыта, аннан Казан педагогия институтының Көнбатыш әдәбиятлары кафедрасында ассистент булып эшли. Бирердәге педагогик хезмәте аңа Европа сүз сәнгатен, эстетикасын, фәлсәфәсен тирәнрәк үзләштерергә, алдагы тикшеренүләрендә татар әдәбиятын дөнья әдәби контекстында карарга ярдәм итә. 1941 елда Х. Госманның М. Горький музеенда әдәби хезмәткәр вазифасын башкаруы да билгеле.

Бөек Ватан сугышы башлангач, русның күп кенә әдип-галимнәре, сәнгать әһелләре тылга озатылып, аларның зур төркеме Чистай, Казан калаларында яши. Ә фронтка киткән күпсанлы татар зыялылары арасында Х. Госман да була. Ул 1941 елның 13 июлендә сугышка китеп, 1946 елның 6 маенда гына тыныч хезмәткә әйләнеп кайта. 5 ел эчендә офицер дәрәҗәсендә Х. Госман төрле сугышларда, шул исәптән Германия җирендәге катлаулы бәрелешләрдә дә катнаша, штабта, төрле фронт газеталарында («Ватан өчен» һ. б.) эшли, политхезмәткәр дә була. Күрсәткән батырлыклары өчен «Кызыл Йолдыз» ордены, «Германияне җиңү өчен», «Кенигсбергны алу өчен» һәм башка медальләр белән бүләкләнеп, сугышны капитан дәрәҗәсендә төгәлли.

Х. Госман – 1946–1951 елларда Казан педагогия институтының Көнбатыш әдәбиятлары кафедрасында өлкән укытучы. 1951 елда, «Һади Такташның эстетик идеяләренең үсеше» темасына диссертация яклап, ул филология фәннәре кандидаты дигән гыйльми дәрәҗә алуга ирешә. Шушы ук елда галим эшчәнлегенең Казан дәүләт университеты белән бәйләнешле чоры башланып, бирегә ул татар теле һәм әдәбияты кафедрасы мөдире итеп чакырыла. 1960 елда бу кафедра икегә – татар теле һәм татар әдәбияты кафедраларына аерылгач, ул әдәбият кафедрасын 1975 елның августына кадәр җитәкли. 1962 елда ул «Социалистик революция һәм татар поэзиясе» темасына докторлык диссертациясе яклый һәм 1964 елда профессор таныклыгын ала. 1975–1989 елларда галим татар әдәбияты кафедрасының профессор-консультанты вазифасын башкара.

Х. Госман татар әдәби-мәдәни дөньясына 1930 еллар башында шагыйрь буларак килеп керә. «Х. Госманда сүз сәнгатенә мәхәббәт балачагында ук тәрбияләнә. Алар гаиләсендә китап, әдәбият культы яши. Олы абыйсы Таһир Госман-Сулмаш (1900–1983) – билгеле язучы була. Аның повестьлары („Күпер“, „Семафор“), хикәяләре 1920–1930 еллар укучыларында зур кызыксыну уята. Моннан тыш, Х. Госман – эмоциональ, шигъри җанлы кеше. 1931 елда Казанда аның беренче шигырьләр җыентыгы нәшер ителә („Кырлар лирикасы“ [Госман, 1931]» (тәрҗ. безнеке. – *Х. М.*) [Миннегулов, с. 5]. 1960 еллар ахырында Хатип ага Госман галимнәр тормышы турында роман яза башлавын искәрткән иде. 1930–1940 елларда, ягъни егерме ел буена әдәби иҗат белән актив шөгыльләнү, аңа фәнни тикшеренүләрендә сүз сәнгатен тирәнрәк аңларга һәм аңлатырга, шигърияттнең серен, тәэсир көчен ныграк ачарга ярдәм итеп, үзенә күрә бер әзерлек мәктәбе була.

Х. Госман соңгы дәвер мәдәни җәмәгатьчелегенә, иң беренче чиратта, олуг әдәбиятчы галим, мөхтәрәм педагог-остаз буларак билгеле. Аның төп тикшерү объекты булып XX гасырның 10–20 еллар татар поэзиясе, бу яңарыш чорының төп вәкилләре Г. Тукай, М. Гафури, Ш. Бабич, Һ. Такташ, Х. Туфанның шигъри дөньялары тора. Аның диссертацион тикшерүләре нигезендә «Бөек Октябрь революциясе һәм Гражданнар сугышы чорында татар поэзиясе» [Госман, 1960], «Егерменче елларда татар поэзиясе» [Госман, 1964] исемле монографияләре дөнья күрде. Бу хезмәтләр, теге яки бу дәрәҗәдә үзгәртелеп, тулыландырылып, камилләштерелеп «Шигърият гомере» [Госман, 1978] һәм «Олы юлга чыкканда» [Госман, 1982] исемнәре белән кабат та басылып чыктылар.

Х. Госман, фикер тирәнлеге, зур көч сорый торган төрки-татар шигырь төзелешен өйрәнүгә алынып, бу юнәлештә аеруча нәтиҗәле эшли һәм саллы-саллы хезмәтләрен чыгара: «Татар шигыре (тарихи күзәтү)» [Госман, 1964], «Шигырь төзелеше» [Госман, 1973], «Древние истоки тюркского стиха» [Усманов, 1984], «Тюркский стих в средние века» [Усманов, 1987] һ. б. Галимнең мәкалә-хезмәтләренә фәнни-теоретик тирәнлек, полемик рух, әдәбитарихи процесс белән тыгыз бәйләнеш хас. Автор татар сүз сәнгатенең тарихи үсешендә аңа башка әдәбиятларның теге яки бу дәрәҗәдә тәэсире булуын танып, әдәби бәйләнешләрнең һәм йогынтының әһәмиятен дә күрсәтә. Әмма, галим фикеренчә, төрки-татар шигыре, иң беренче чиратта, үзенең эчке казанышларына, сөйләм ритмикасына, мәкаль-әйтемнәргә нигезләнеп формалашкан, үскән һәм бөек Тукайларны тудырырлык дәрәҗәгә ирешкән. Х. Госманның төрки-татар шигыре турындагы теоретик карашлары татар дөньясында гына түгел, ә бөтен тюркология фәнендә танылган.

Докторлык диссертациясен яклагач, Хатип Госман Борынгы һәм Урта гасыр әдәби мирасы белән кызыксынуын тагын да арттыра. «Аның турыдан-туры катнашында 1969 елда Урта гасыр шагыйре Котбның „Хөсрәү вә Ширин“ поэмасы гарәп хәрефләре белән ике кисәктә басылып чыга. 1970 елда шәрех-аңлатмалар белән ундүртенче йөз шагыйре Хисам Кятибнең „Җөмҗөмә солтан“ дастаны, 1980 елда, Зәйнәп Максудова белән берлектә, ул Сәйф Сараиның „Китабе Гөлестан бит-төрки“ кулъязмасындагы текстларны гарәп хәрефләре белән бастырып чыгара» [Даутов, Рахмани, б. 407]. 1966, 1967 елларда XIV һәм XVIII йөз шагыйрьләренең әсәрләрен үз эченә алган ике әсбап дөнья күрә. Х. Госман катнашында югары уку йортлары өчен язылган «Әдәбият теориясе» [Госман, Мәҗитов], урта гомуми белем бирү мәктәпләренең X сыйныф укучыларына адресланган «Әдәбият» дәреслеге дә бар.

Х. Госман гыйльми һәм педагогик эшчәнлектән тыш, үз чорының күренекле җәмәгать эшлеклесе дә иде. Ул даими рәвештә төрле дәрәҗәдәге киңәшмә-җыелышларда, конференция-корылтайларда фән, милли мәдәният һәм

мәгарифнең мөһим мәсьәләләре, милләт язмышы хакында чыгышлар, докладлар ясады. Халыкара форум-конгрессларда татар кавеменең, фәненең дәрәҗәсен югары тотты. Миңа 1997 елда Алма-Атада Мохтар Ауэзовның тууына 100 ел тулу тантаналарында катнашырга туры килде. Бу бөек әдипнең 60 еллыгында, ягъни 1957 елда Татарстаннан вәкил булып Хатип ага Госман катнашуы ачыкланды. 40 ел вакыт үтүгә карамастан, казакъның өлкән буын әдип-галимнәре аның ялкынлы, тирән эчтәлекле чыгышларын хәтергә төшерделәр. Аның киңкырлы белеме, шигъри сүзне нечкә тоемлау сыйфаты илебезнең, аеруча төрки дөньяның зур галимнәре белән аралашырга һәм хезмәттәшлек итәргә мөмкинлек бирә.

Филология фәннәре докторы, профессор, «ТАССРның атказанган фән эшлеклесе», «Кызыл Йолдыз» һәм «Почет Билгесе» орденнары кавалеры, әдип, галим, педагог, журналист һәм җәмәгать эшлеклесе Хатип Госман улы Госманов – халыкка, милләткә каһарманнарча хезмәт итүнең күркәм бер үрнәге.

**Әдәбият**


*Госман Х.* Бөек Октябрь революциясе һәм Гражданнар сугышы чорында татар поэзиясе. Казан: Казан ун-ты нәшр., 1960. 182 б.

*Госман Х.* Егерменче елларда татар поэзиясе. Казан: Казан ун-ты нәшр., 1964. 397 б.

*Госман Х.* Кырлар лирикасы: шигырьләр. Казан: Татиздат, 1931. 36 б.

*Госман Х.* Олы юлга чykканда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1982. 256 б.

*Госман Х.* Татар шигыре: тарихи күзәтү. Казан: Татар. кит. нәшр., 1964. 156 б.

*Госман Х.* Шигърият гомере. Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. 208 б.

*Госман Х.* Шигырь төзелеше. Казан: Татар. кит. нәшр., 1975. 132 б.

*Госман Х., Мәҗитов З.* Әдәбият теориясе. Әдәби әсәр: Урта мәктәпләрнең тел-әдәбият укытучылары, студентлар һәм югары класс укучылары өчен кулланма / Проф. И. Нуруллин ред. Казан: Татар. кит. нәшр, 1980. 143 б.

Хатип Госман // Әдипләребез: биобиблиографик белешмәлек: 2 томда: 1 т. / Төз. Р. Н. Даутов, Р. Ф. Рахмани. Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. 404–408 б.

*Миннегулов Х. Ю.* Хатип Усманович Усманов (Выдающиеся ученые Казанского университета). Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2002. 20 с.

*Усманов Х. У.* Древние истоки тюркского стиха: учебное пособие. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1984. 152 с.

*Усманов Х. У.* Тюркский стих в средние века. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1987. 147 с.